| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 08.07.2021 | п.г.т. Алексеевское | № 29 |

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсендәге 1 өлешенең 20 пункты, Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

**Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 21 гыйнварындагы 108 номерлы Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренә» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Шәһәр төзелеше регламентлары» 3 бүлегенең «Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары» 38.1 маддәсендә таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Параметрларның төрләре һәм үлчәү берәмлекләре | | | Күчемсез милекне файдаланунының төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрларның әһәмияте | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Аерым бер гаилә йорты | Күп балалы йортта бер гаиләгә исәпләнгән торак берәмлек |
| **Җир кишәрлекләренең чик параметрлары** | | | | |
| Дәүләт яисә муниципаль милек | Минималь мәйдан | кв.м | *1000* | 1000 |
| | Максималь мәйдан | кв.м | *1500* | 1500 |
| Шәхси милек | Минималь мәйдан | кв.м | *1000* | 1000 |
| | Максималь мәйдан | кв.м | *2500* | 1500 |
| Урам (юл йөрү) фронты буйлап минималь киңлек | | м | 12 | 6 |
| **Участоклар чикләрендә рөхсәт ителгән төзелешнең соңгы параметрлары** Участок төзелешенең максималь проценты | | % | 45 | *45* |
| Участокның алгы чигеннән корылмаларның минималь чигенеше (башка күрсәткеч төзелешне җайга салу линиясе белән билгеләнмәгән очракларда) | | м | *3* | 3 |
| Участокның ян чикләреннән корылмаларның минималь чикләре | | м | а) 1 - брандмауэр дивар мәҗбүри булганда;<br>б) 3 - башка очракларда | а) 0 - күрше блокларга кушылган очракларда;<br>б) 3 - башка очракларда |
| Участокның ян чикләреннән корылмаларның минималь чикләре | | м | 3 | 3<br>(төзелеш эшләрен җайга салу линиясе башкача билгеләнмәгән булса) |
| Төзелешләрнең максималь биеклеге | | м | 12 | 12 |
| Җир участоклары киртәләренең максималь биеклеге | | м | 2,5 | *1,8* |

2) «Шәһәр төзелеше регламентлары» 3 бүлегенең «Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары» 38.1 маддәсендә түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:

«3. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

Дәүләт яисә муниципаль милектәге җирләрдән төзелә торган җир кишәрлекләренең минималь күләме «индивидуаль торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» - 1 000 кв.м.

Дәүләт яисә муниципаль милектәге җирләрдән төзелә торган җир кишәрлекләренең максималь күләме «индивидуаль торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» - 1 500 кв.м.».

Шәхси милектәге җирләрдән барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең минималь күләме «индивидуаль торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып

бару өчен» - 1 000 кв.м.

Шәхси милектәге җирләрдән барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең максималь күләме «индивидуаль торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» - 2500 кв.м.».

2. Әлеге карарны «Территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасы» (https://fgis-tp.ru) рәсми сайтында һәм Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары В.В. Увакинага йөкләргә.

**Алексеевск шәһәр**
**җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**